Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

19 ноябрь 2019 ел № 3

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 19 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Васильевка авылы мәдәният йорты бинасы фасадын ремонтлау һәм тәрәзәләрен алыштыру (чыгым материаллары, металлосайдинг, тәрәзә блоклары һәм комплектлау детальләре сатып алу очен) мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Васильевка авылы, Үзәк урамы, 26 йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Халык җыенында рәислек итүче
Васильевка авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Касыймуллин